

# Сугыш кырында ятып калдылар

**Бу язма Рус Тимерлеге авылыннан Долговлар гаиләсенең фаҗигале язмышы турында. Бөек Ватан сугышыннан Агафья Гавриловна һәм Иван Иванович Долговларның 6 улы һәм 2 оныгы әйләнеп кайта алмады. Бу язма «Хәтер китабы» эзләнү группасы материаллары буенча хәзерләнде.**

Сугышчан дан юллары буенча Бөтенсоюз походының ВЛКСМ райкомында урнашкан район штабына Куйбышевта яшәүче хезмәт ветераны Бажутовтан хат килеп төшә. Ул элек Тимерлек авылында яшәгән һәм эшләгән А. В. Трофимова сүзләренә таянып, түбәндәгене хәбәр итә: «Иван Иванович Долговның 12 улы һәм бер кызы сугыш кырыннан кайтмавы, аларның бөтенесе яу барышында батырларча һәлак булуы турында Татарстан АССР тарихында билгеләмә икән». Хатта ук берничә исем дә китерелә.

Мондый фактка битараф калу мөмкинме соң? Эзләнү группасы эшкә керешә.

Тимерлеккә баргач, авыл Советы рәисе белән әңгәмә барышында, бу авылда әнисе Евдокия белән Юрий Яковлевич Долгов яшәвен белдек. Юрий үзе 1940 елгы, билгеле ки, бернәрсәне дә белми һәм белә алмый. Әнисе Евдокия каты **чирли, ире** Яковны һәм ике баласын югалтудан фикерләү сәләте калмаган, берни хәбәр итә алмый. Бернинди фронт хатлары, үлү турында килгән хәбәрләр дә сакланмаган. Әмма иң гаҗәбе шул, авыл Советында Бөек Ватан сугышында үлүчеләр исемлегендә Долговлар фамилиясе гомумән юк булып **чыкты.**

Без шул вакытта ук Октябрь районы хәрби комиссариатына мөрәҗәгать иттек. Долгов фамилияле барлык кешеләр арасыннан әтиләре Иван булганнарын сайлап алдык. Алар 1903 елда туган Яков Иванович (1941 елның 10 сентябрендә мобилизацияләнгән), 1924 елда туган Нина Яковлевна (1942 ел, 30 август) һәм 1926 елгы Иван Яковлевич (1943 ел, 8 ноябрь) иде. Туган еллары буенча исәпләп караганда Яков Иванович Долговның өлкән улы, ә Нина һәм Иван Яковның балалары дип фараз итәргә була. Шулай хәл әзрәк ачыкланды. Ә калганнары кемнәр һәм алар ничәү?

Тимерлек авылы ул вакытта Тельман районына керә. Аның хәрби комиссариаты эшләрне Октябрь районына тапшырганда архив документларына карата үтә җавапсызлык күрсәтә, аларның бер өлеше юк ителә, икенчесе югала. Шул сәбәпле Долговлар гаиләсеннән фронтка тагын кемнәр мобилизацияләнгән булуын ачыклавы мөмкин булмады.

Оборона министрлыгының Үзәк архивыннан безнең сорауга җавапны 9 ай көтәргә туры килде. Аңа кадәр паспорт өстәленнән алынган мәгълүматлар буенча Норлатта яшәүче Долговлар белән очрашып чыктык. Аларның берсе дә без эзләгән гаилә белән туганлык мөнәсәбәтендә тормый иде.

Социаль тәэминат бүлегенә мөрәҗәгать иттек. Үлгән туганнары өчен пенсия алучы 12 Долгов арасыннан безне Тимерлек авылында яшәүче Евдокия Федоровнаныкы игътибарны җәлеп итте. Ул югалган ире Яков өчен дүрт баласы—Николай, Александр, Валентина, Юрийга (өлкәннәре Нина һәм Иван бу вакытта сугышта була инде) пенсия ала. Шунда ук Тельман районы хәрби комиссариатының:

«Сезнең ирегез Яков Иванович 1942 елның апрелендә хәбәрсез югалды» дип 1947 елның 26 маенда бирелгән хәбәре дә эшкә теркәлгән булып чыга.

Тимерлек авылына чираттагы баруда Юрий белән әңгәмә вакытында Нинаның җәрәхәтләрдән үлүен, ә Валентинаның Ташкентта яшәвен белдек. Ул аның адресын да бирде. Аңа хат яздык, ләкин җавап алмадык. Икенче тапкыр язу да файда бирмәде. Шуннан соң Ташкенттагы адрес бюросына һәм Ташкент пионерлар йортының эзтабарларына мөрәҗәгать итәргә булдык. Бары 4 айдан соң гына, ниһаять, хат алдык. «Бөек Ватан сугышы фронтларында минем әтием Яков, абыйларым Павел, Сергей, Петр, Алексей һәлак булдылар. Миндә әтием һәм абыем Иванның хәбәрсез югалулары турында документлары күчермәсе генә саклана. Апам Нина сугыш тәмамлануга минем янга кайтты һәм озакламый җәрәхәтләреннән үлде». Шуннан Иванның да (Яковның улы) хәбәрсез югалганлыгы ачыкланды. Икенче оныкның Нинаның язмышы да тулыланды.

Долговлар гаиләсе составын ачыклауда ЗАГС бүлеге булышлык итәргә мөмкин иде. ЗАГС бүлеге мөдире Т. Сиплатова безгә яхшы ярдәм күрсәтте. Ул гасыр башындагы барлык эшләрне, чиркәү кенәгәләрен (революциягә кадәр һәм аннан соң да 20 нче елларда чиркәүдә чукындырганда язма теркәү үткәрә) тапты. Бихисап күп битләрне актарырга һәм безне кызыксындырган мәгълүматларны берәмтекләп җыярга туры килде. Яковның 1903, Аннаның 1905, Елизаветаның 1907, Сергейның 1911, Петрның 1913, Алексейның 1918, Клавдиянең 1926, Николайның 1928 елда туганлыгы ачыкланды. Әмма ачылып җитмәгәннәр дә калды—туганнар сан ягыннан моннан артык бит әле.

Тимерлеккә чираттагы баруда авылның өлкән кешеләре Морозова, Шмитов, Солдатихин, Грачев, Сашина һәм башкалар белән әңгәмә өстәмә ачыклыклар кертте. Алда телгә алынганнардан тыш Павел, Александр һәм Анастасия—барлыгы 11әү, шул исәптән 7 малай һәм 4 кыз булганнар икән Долговлар.

Бу гаилә туганнарын эзләп Стекольный поселогына баргач, моны Иван Ивановичның бертуганының кызы Александра Федоровна да раслады. Һәм, иң мөһиме, бертуганнарның берсенең—Сергейның хатынының адресын бирде. Ул Яңа Тумбада яши иде.

Анда ике тапкыр барырга туры килде. Беренче катында КПСС райкомы секретаре А. А. Коростелев белән бардык. Хәзер ничектер, әмма март аенда урман юлы безнеке селкеде. Кызганычка каршы, без аны туры китерә алмадык, улы янына Балаковога киткән булып чыкты. Безгә биргән адрес буенча хат яздык, үзенә мәгълүм булганнар турында язып җибәрүен, фронт хатларын, Долговларның гаилә фотоларын, иренекен дә салуын үтендек. Озак көтәргә туры килсә дә, тулы эчтәлекле хат алдык:

«Долгов Иван Иванович һәм Агафья Гавриловна 11 бала тәрбияләп үстерәләр. Аларның 7 улы фронтка китә. Яков, Сергей, Петр өйләнгән иделәр инде. Минем ирем Сергей «Кызыл Йолдыз» колхозында рәис булып эшләде. 1939 елда фин сугышына алынды һәм 1940 елның 10 мартында һәлак булды. Документлары янгын вакытында юкка чыкты. Үлү турындагы хәбәре генә саклана. Иремнең дә фоторәсеме бар. Аның туганнарының кайсысы кайчан үлгәнен хәтерләмим инде».



**Рәсемдә: Долговларның 6 улларының берсе Сергей. Ул да ил азатлыгы өчен көрәштә һәлак була.**

Безне Юрийдан килгән хат та сөендерде. Ул Нинаның фронтта төшкән фоторәсемен тапкан һәм җибәргән булып чыкты.

Ниһаять, 9 ай үткәч, СССР Оборона Министрлыгы Үзәк архивыннан җавап килде.

«237 нче укчы дивизиянең отделение командиры старшина Алексей Иванович Долгов 1943 елның 3 сентябрендә һәлак була. Сумск өлкәсенең Синевс районы Андреевский Байрак авылында күмелгән. Соңгы вакытта Синевск районы Липоводолинск районы составына кушылды, өлешчә Полтава өлкәсенә күчте.

Рядовой Долгов Яков Иванович, туган елы 1903, 1942 елның апрелендә хәбәрсез югала.

Сораган башка кешеләр турында бүлектә мәгълүматлар юк. Бүлек начальнигы Синенко».

Ә калганнарның язмышы ничек тәмамлана соң? Иванга килгән хәбәр дә табыла—«1943 елның 6 декабрендә хәбәрсез югалды».

Алексей һәм Петр яшьләре, сугышта катнашучы ветераннар белән әңгәмәләр, шулай ук туганнарының хатлары буенча да Кызыл Армия сафларына сугыш башланганчы чакырылалар, Ерак Көнчыгышта хезмәт итәләр һәм фронтка шуннан эләгәләр. Павел һәм Александрга килгәндә исә, кызганычка каршы, Тельман районы хәрби комиссариаты тарафыннан мобилизацияләнгәннәр исемлеге югалу сәбәпле, мәгълүматлар туплап булмады. Алар ише миллионнарча билгесез солдатлар турында Үзәк архив (һәлак булганнар, җәрәхәттән үлүчеләр, хәбәрсез югалганнар исемлегендә исәпләнми» дип кенә җавап бирә. Әйтерсең җирдә андый кешеләр гомумән булмаган. Ә бит алар да булган, яшәгән.

Бу уңышсызлыкка очрагач бүләкләү бүлеге аркылы эш итеп карарга булдык. Бәлки анда аларның эзенә төшеп булыр. Бу юлы җавап чагыштырмача тиз алынды.

Линоводолинск районы хәрби комиссарыннан Алексей Долгов күмелүенә кагылышлы безнең сорауга түбәндәге җавап килде: «Линоводолинск районының Байрак авылында үлүчеләр исемлегендә Алексей Иванович Долгов юк. Элекке Синеевск районында Андреевск Байрагы да юк. Мәгълүм булсын өчен Сумск өлкәсенең чиктәш Лебединск районында шулай ук Байрак авылы булуын хәбәр итәбез».

Анда сорау җибәрдек. Аннан алынган җавапта түбәндәгеләр хәбәр ителә:

«Алынган белешмәләр буенча немец-фашист илбасарлары белән сугышта һәлак булган иптәш Долгов А. И. Сумск өлкәсенең Лебединск районы Михайловск авыл Советы Байрак авылындагы туганнар каберлегенә күмелгән. Кабергә Андреевск сигезьеллык мәктәбе шефлыкны гамәлгә ашыра.

Михайловск авыл Советына һәм Андреевск мәктәбенә туганнар каберлегенең фотосурәтен сорап җибәргән үтенечебезгә әлегә җавап алынмады.

Долговлар гаиләсенең язмышы шулай ачыкланды. Аларның 6 уллары—Яков, Сергей, Петр, Алексей, Александр, Павел, 2 оныклары—Нина һәм Иван сугыш кырыннан әйләнеп кайта алмыйлар. Алар Бөек Җиңү хакына, Ватан азатлыгы һәм намусы хакына гомерләрен корбан итәләр. Җиденче уллары Николай яше буенча армиягә чакырылмый кала. Ул сугыш тәмамланганнан соң Куйбышев шәһәрендә юл авариясенә эләгә һәм һәлак була. Калган балалары төрле елларда үләләр. Улларын көтеп ала алмаган әти-әниләре авыр хәсрәттән вакытыннан алда гүр иясе булалар. 1973 елда Яковның хатыны Евдокия дә дөньядан китә.

Долговлар гаиләсе. Рус Тимерлеге авылында бу зур гаилә членнарын хезмәт сөючән, әйбәт гаилә итеп искә алалар.

«Барлык туганнар да колхозда эшләделәр. Намуслы эшләделәр. Барысы да яхшы кешеләр иде. Өчесе—Алексей, Павел, Александр комсомоллар иде, авыл тормышында актив катнашып килделәр»,—дип искә ала А.М. Долгова.

«Петр авылда беренче гармончы иде. Бер генә кичә дә аннан башка узмады». (А. М. Солдатихин).

«Сугышка кадәр авылда булганда яшьләр уеннарында, клубта үзешчәннәр белән бергә гармонга кушылып җыр, такмаклар башкаруларын бер генә тапкыр тыңларга туры килмәде. Еш кына аннан соң да ул сандугачларыгыз кайда соң әле дип сорый торган идем (элекке прокурор Сидоров).

«Минем абыем Иван балалайкада бик яхшы уйный иде» (Валентина).

Краснодар краеның Тимәш авылында Степанова Епистимия Федоровнаның фронтта үлгән тугыз улына һәйкәл-ансамбль куелган. Безгә дә Долговларның 6 улын һәм 2 оныгын шул тәртиптә мәңгеләштерү турында уйларга ярамасмы соң?!.. «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый» дигән сүзләр телдә генә калмаса иде.

**И. САНДЛЕР,**
«Хәтер китабы» эзләнү отряды җитәкчесе.

# Аклану юк

Газиз баланны югалтудан да авыррак хәсрәт юк, диләр халыкта. Мондый ачы язмышны татыган кеше әлеге әрнүне һәм өметсезлекне гомеренең соңгы мизгеленәчә онытмый. Һәрбер очрак, кечкенә генә сәбәп тә аңа үткәненең иң кадерле, әмма кире кайтмас чагын —мәрхүм баласының исән вакытын хәтерләтәчәк.

Бу көннәрдә апалы-сеңелле Атяшеваларның фаҗигале үлеме һәммәбезне тетрәндерде. Алар суга батып вафат булдылар.

Җәй башыннан бирле безгә «суга баткан» дигән шушы хәтәр сүз белән ничәмә-ничә тапкыр очрашырга туры килде инде. Әмзәдән тугыз яшьлек кызчык Т. Щелкова да, Ключи поселогыннан алты яшьлек И. Анисимова, Норлаттан 14 яшьлек А. Тверсков та, әбисенә кунакка кайткан тугыз яшьлек И. Шәһитов һәм тагын кайберәүләр шушы язмышка дучар булдылар. Әмма иң аянычы, иң әрнүлесе—10 суга бату очрагының 7 сендә балалар гомере өзелде бит. Күңел ачарга чыккан, бераз «кәефләнеп» алган кампания членнары түгел, нәкъ менә әле яшәргә дә өлгермәгән сабыйлар фаҗигага юлыкты. Киләчәктә безнең күз текәп торган тәрбиячеләребез—өметебез булган сабыйлар бит алар. Ә эти-әниләре ятим калдылар.

Мондый очракта халыкта: «Язмыштан узмыш юк инде. Маңгаеңа ни язылган—шуны күрәсең», —дип юату гадәткә кергән.

Чынлыкта да шулаймы соң бу? Болай да олы хәсрәткә дучар булган ата-аналарга әрнү өстисем килми. Әмма, дөрес аңлагыз, югарыда телгә алынган фаҗигале очраклардан күренгәнчә, өлкәннәрнең балалар турында кайгыртмавы көн кебек ачык.

Беренче чиратта бу—балаларның һәм яшүсмерләрнең җәйге ялын оештырмау, көндәлек тормышы үзагымга куелуы нәтиҗәсе. Урыннардагы җитәкче иптәшләрнең балалар ялы кебек җитештерүгә файдасы булмаган «вак-төяк»ләр белән шөгыльләнергә теләмәүләре дә сәбәпче моңа. Безгә дә әйләнә-тирәбездәге тормышка зуррак игътибар белән карарга бик вакыт: ай ярым эчендә фаҗигага юлыккан җиде бала — аларның эти-әниләре һәм якыннарының сүрелмәс хәсрәте генә түгел, без—олыларга карата коточкыч гаепләү дә ул!

Шәһәрдә балаларның җәйге ялын оештыру мәсьәләләре белән беркем дә шөгыльләнми. Инде ничә ел буена сүз алып барыла торган шәһәр бассейны шулай ук беркемгә кирәкми. ОСВОД (суга батканнарны коткару җәмгыяте)—шундый оешма да бар бездә— әмма ул кәгазьдә генә бар санала. Тагын кемгә өметләнергә мөмкин? Комсомолгамы? Аның үзенә ярдәм һәм таяныч кирәк әле.

Менә безнең мөмкинлекләр шул гына. Бүгенге көндә күп кенә оешмаларда, предприятиеләрдә, хәтта авыл җирләрендә дә зур бәһага төшереп төзелгән сәламәтләндерү комплекслары бар. Әлбәттә, болар мактауга лаек. Әмма бүгенге көндә безнең шәһәрдә дә, районда да суга бату очракларын кисәтү белән шөгыльләнгән бер генә берәмлек тә юк. Урыннарда коткару чаралары булдыру, елга-сулыкларның аеруча куркыныч урыннарын яки коену өчен уңай булган куркынычсыз җирләрне шартлы тамгалар белән билгеләп кую мөмкин эш түгелмени соң? Боларны эшләү өчен шулай зур чыгымнар кирәк микәнни?

Теләгән очракта мондый гына эшләрне урыннарда (авылларда) шул ук хуҗалык вәкилләре—үз сулыкларының тирәнлеген, мәкерле урыннарын яхшы белүчеләр дә эшләп куя ала бит.

Безнең уйсыз, битараф булуыбыз, тиеннәрне экономияләвебез никадәр кыйммәткә төшә, бу хакта уйлаганыгыз бармы? Үз балаларыбызның гомере белән түлибез; ләбаса. Быелгы җәйнең ачы сабагы безне акылга утыртырга тиештер.

Сүземнең ахырында гел эш белән мәшгуль булган, эшлекле эти-әниләргә, йомшак күңелле әби-бабайларга һәм күрше-күләнгә шуны әйтәсем килә: әгәр сез, бик аз гына вакытка булса да бала белән шөгыльләнүне ышандырып үз өстегезгә аласыз икән, бу максатыгыздан читкә тайпылырга хакыгыз юк. Балаларның үзләрен генә су коенырга җибәрмәгез. Чөнки теләсә кайсы минутта фаҗига килеп туарга мөмкин. Ә мондый бәладән аклану юк.

**Ю. МУРАКАЕВ,**
Октябрь районы прокуроры, юстиция советнигы.

# Телевидение

**ШИМБӘ**
**13 ИЮЛЬ**

**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 Мультфильм.
17.15 «Бергәләп өйрәник».
17.45 «Гитлер һәм Сталин». Док. фильм (М.).
18.45 Россиянең парламент хәбәрчесе.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Телесеанс».
20.30 «Әлли-бәлли-бәү».
20.45 Г. Исхакый. «Тормышмы бу?!» Әдәби театр.
21.25 Реклама.
21.35 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Концерт.
6.45 «Экранда— Себер». Киножурнал.
6.55 Док. фильм.
7.20 Мультфильм.
7.30 Ритмлы гимнастика.
8.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
8.30 «ТЯХ».
8.45 Музыкаль фильм премьерасы.
9.20 Режиссер Б. Шәмшиев фильмнары. «Ысык-Күлнең ал мәкләре».
11.00 «Иртәнге йолдыз».
12.00 А. Н. Островский. «Талантлар һәм баш июучеләр». Фильм-спектакль.
13.45 «50х50».
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Кырыгынчы... язмышны билгеләүче...» 3 нче фильм.
16.30 «Җир—уртак йортыбыз». Фотоконкурс.
16.35 Рәссам А. Захарченко.
16.50 «Яңа исемнәр». Музыкаль программа.
17.35 Мультфильм.
18.00 Халыкара панорама.
18.45 Концерт.
19.35 Нәфис фильм премьерасы. «Кыска уен».
21.00 «Вакыт».
21.40 «Җыр-91».
22.45 «ТЯХ».
23.00 «Александр-шоу».
01.00 Нәфис фильм премьерасы. «Кыска уен».
02.25 Николай Гедда концерты.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 «Сәламәтлек».
8.45 Док. фильм.
9.30 «Дуслык» видеоканалы.
12.00 «Плюс унбер» видеоканалы.
14.00 Режиссер М. Дохматская фильмнары.
14.40 «Спорт һәркем өчен».
14.55 «Җәлил һәм музыка». Казаннан тапшыру.
15.35 Док. фильм премьерасы.
15.55 «Алиса». Мәдәният буенча халыкара журнал.
16.50 Мультфильм.
21.40 «Тилергән солдатлар». Нәфис фильм.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 «К-2» Мәскәү кинофестивалендә.
23.45 «Коллаж».
23.50 Мәскәүнең халыкара дөнья марафоны.

**ЯКШӘМБЕ**
**14 ИЮЛЬ**

**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 «Авантюрист әфәнделәр». Нәфис фильм.
18.25 Реклама.
18.30 «Панорама». Информацион-публицистик программа.
19.30 «Яшьләр иҗаты».
20.15 «Әлли-бәлли-бәү».
20.25 «Бенефис». РСФСРның атказанган артисткасы Ирина Хәкимова.

**I ПРОГРАММА**

8.00 «С» формуласы.
8.30 Биржа яңалыклары.
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 «Иртә таңнан».
10.00 «Ватанга хезмәттә».
11.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
11.30 «Сәяхәтчеләр клубы».
13.00 «Музыкаль киоск».
13.30 «Франция һәм французлар». Кинопрограмма.
14.20 Мультфильм.
14.30 «Веди».
15.00 «ТЯХ».
15.15 В. Симон А. Аренский әсәрләрен башкара.
16.35 Ф. Мендельсон. Фортепиано белән оркестр өчен концерт.
17.05 «Авыл сәгате».
18.05 «Авазлар күп — дөнья бер».
18.10 «Уолт Дисней тәкъдим итә...»
19.00 Док. фильм премьерасы.
19.30 «Сирано де Бержерак». Нәфис фильм.
21.00 «Вакыт».
21.40 «Кинопанорама». Информацион чыгарылыш.
21.55 «Футбол күзәтү».
22.25 «Христофор». Минск сатира һәм юмор театры ангажементы.
23.45 «ТЯХ».
00.00 «Хронограф».
00.15 «Моны булдыра аласыз».
01.00 «Сезне Вячеслав Малежик чакыра».

**II ПРОГРАММА**

8.00 «Зарядкага басыгыз!»
8.15 Фәнни-популяр фильм.
9.10 «Көзге корабль».
9.30 «Дуслык» видеоканалы.
12.00 Фил Донахью программасы.
12.50 Маринский балетының тарихы. 2 нче кисәк.
13.50 «Мәхәббәт турында берничә минут».
14.00 Мультфильм.
14.10 Телеспектакль премьерасы.
15.55 Док. фильм.
16.55 «Коллаж».
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 «К-2» Мәскәү кинофестивалендә.
23.40 «Шәһәр аша бару». Нәфис фильм.

# Казанның авыр юлы

«Дуслык» газетасының бер санында Норлат—Казан, Казан—Норлат пассажир автобусы йөриячәге, зур автобус (билгеле инде, комфортабельле) булачагы турында язылган иде.

Табигый ки, бу хәбәр шәһәр һәм авыл халкын бераз сөендерде. Чөнки Казанга 185 нче номерлы поезд йөрүдән туктады, самолет очмый.

Ләкин сөенечләр көенечкә әверелде. 8 июль көнне Казанга инде, халык әйтмешли, көнен күргән, иске, кечкенә автобус китте. Ул нибары 15—16 кеше алды. Кайда соң вәгъдә ителгән зур автобус? Әлеге кечкенә, уңайлыклары булмаган автобуста нәни балалы аналар, олы яшьтәге кешеләр Казан кадәр Казанга ничек барып җитәргә тиешләр соң?! Юл хакы түләп тә әйберләрне куяр урын да булмаганда бу ара бик ерак булып тоелыр кешеләргә.

Билгеле, автовокзал ишек төбендә сумкаларын күтәреп автобус көтүчеләр халык турында мондый «кайгыртучанлык» күрүчеләрне тетепме-тетәләр. Һәм бу аңлашыла да. Әле тагын 8 сәгать 40 минутта китәсе автобус унынчы 5 минутта гына кузгалды.

Бу мәсьәләгә автовокзал начальнигы иптәш И. Канәфин һәм моңа җаваплы башка кешеләр ничек карыйлар икән?

**И. ЕРЕПОВ.**

РЕДАКЦИЯДӘН: Хатны алу белән автовокзал начальнигы И. Канәфин белән элемтәгә кердек. Әйе, ул пассажирлар йөртү мәсьәләсенең аянычлы булуын таный. «Норлаттан бер көнне ЛАЗ-695 автобусы китсә, икенче көнне кечкенә автобус җибәрергә мәҗбүр булабыз. Вәгъдә ителгән ЛАЗ автобусы әлегә юк. Тик без кул кушырып утырмыйбыз, көн саен Казан белән элемтәгә керәбез»,—диде иптәш Канәфин. Вәгъдә—иман, ышаныйк шуңа.



**И елгасы, и суы!**
**Ул куагы, таллыгы!**
**Елгасында—балыгы.**
**Бар да дөнья байлыгы**
**И комлыгы, и суы!**

**Төшәсе дә чумасы!**
**Әләксә су анасы—**
**Шунда нәрсә кыласы?!**

**Н. Туганов фотоэтюды.**

## КӨЛЕШЕП АЛЫЙК

—Милиционер малае икәнлегеңне белгәч, Джина сине ташлаган, диләр.

—Дөп-дөрес. Хәзер ул минем үги анам булды инде...

x x x

—Соңгы вакытта нигәдер бик үзгәрдең әле.

—Ә-ә, мин бит хәзер һәр нәрсәгә битараф карыйм, газеталарга язганнарга гына ышанам.

x x x

—Улыгыз институтка кердеме?

—Юк. Беренче имтиханын ук тапшыра алмады. Әмма профессор бик тә мактаган, чөнки безнең улыбыз имтихан тапшыра алмаучылар арасында иң яхшысы булган.

**МӨХӘРРИР Ө. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81,, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Фирдания ХУҖИӘХМӘТОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 83. Тираж 3415.